**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
23.01.2020

**КАРАР**
№ 38

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында 2020 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында**

Балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2020 елда мәктәп һәм студентлар каникуллары чорында балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында»гы 2019 елның 5 мартындагы 158 нче номерлы карары, Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»гы 2019 елның 6 сентябрендәге 791 нче карары нигезендә **КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

1.1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында нигезләмәне (1 нче кушымта).

1.2. Тәтеш муниципаль районында 2020 елга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча муниципаль программаны (2 нче кушымта).

1.3. Тәтеш муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмәне (3 нче кушымта).

1.4. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара муниципаль комиссия составын (4 нче кушымта).

2. Җәйге сәламәтләндерү кампаниясен оештыручыларга үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 3 мартындагы 130 нчы номерлы карары белән расланган (яңа редакциядә) «Балалар һәм яшьләрнең

ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты»на таянырга кирәк.

3. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы вазыйфаларын башкаручыга (Лазарева И.В.) тәэмин итәргә:

- Татарстан Республикасы һәм Тәтеш муниципаль районының профильле сменаларында һәм стационар лагерьларында балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру;

- сәламәтләндерү лагерьларында (мәктәп яны лагерьларында) эш оештыру;

- хезмәт һәм ял лагерьларында эш оештыру;

- 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны укудан һәм каникуллардан буш вакытларында эш бирүчеләр һәм җирле бюджет акчалары хисабына вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

- мәктәп яны лагерьларын, шул исәптән көндезге ял һәм хезмәт лагерьларын әзерләүне 2020 елның 20 маена кадәр тәмамларга, 2020 елның 1 июненә беренче сменаны ачуны тәэмин итәргә.

4. «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе директоры И.Б. Таһированы тәэмин итәргә:

- Тәтеш муниципаль районының «Акчарлак» стационар лагерында балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру;

- Буа, Чүпрәле, Тәтеш, Апас районнары буенча Роспотребнадзор Идарәсенең территориаль бүлегенә «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесенең эше башлануы турында хәбәрнамәне үз вакытында тапшыру;

- 2020 елның 10 мартына кадәр Тәтеш район үзәк хастаханәсе белән медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартнамәләр төзергә;

- 2020 елның 23 мартыннан 2020 елның 22 августына кадәр «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесендә балаларны сәламәтләндерүне һәм ял иттерүне оештырырга;

- квота нигезендә «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесендә юлламаларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә;

- Тәтеш муниципаль районының «Барс» спорт-сәламәтләндерү комплексы» МБУ белән «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесендә ял итүче балалар белән бассейнга бару өчен килешү төзергә;

- профильле сменалар программаларын әзерләргә һәм расларга;

- балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген, хокук тәртибен, санитар-экологик һәм янгын куркынычсызлыгы, суда куркынычсызлыкны, ял һәм аларны савыктыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән санитар-эпидеомиологик чаралар комплексын эшләү һәм үткәрү;

- һәр смена башланыр алдыннан, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, санитар кагыйдәләргә, кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренә, хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау шартларына һәм торышына, ял итүчеләрнең куркынычсызлыгына, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасы җайланмаларының төзеклегенә, янгын турында кешеләргә хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, беренчел янгын сүндерү чараларының таләпләренә туры килүен тикшерү, шулай ук персоналның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүләренә аерым игътибар биреп, сәламәтләндерү оешмаларын комплекслы тикшерү үткәрү;

- урман-техник чаралар үткәрү (агачларның, куакларның түбән үсүче һәм коры ботакларын кисү, яшь үсенте кисү, үлән чабу, коры ауган һәм балаларны савыктыру оешмалары территориясеннән чүп-чар чыгару), дератизация һәм талпанга каршы эшкәртүгә кадәр һәм җәйге сәламәтләндерү кампаниясе барышында, кирәк булган саен, лагерь тирәли 500 метр радиуста чүп-чар чыгару;

- барлык корылмаларны, шул исәптән файдаланылмый торган, ачык территориядә дератизация эшкәртү, лагерь ачылышына 10-14 көн кала 500 метр радиуста сәламәтләндерү учреждениеләре тирәсендәге киртәләрне, аларны консервацияләү алдыннан, шулай ук сменалар арасындагы корылмаларны үткәрү;

- сәламәтләндерү лагере территориясен һәм аның тирәсендәге 50 метрлы зонаны лагерь ачылуга 14 көн кала, шулай ук сменалар арасында талпанга каршы эшкәртү чаралары үткәрү;

- 2020 елның 20 маена кадәр «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесендә барлык сменаларга персоналны билгеләүне тәмамлау.

5. Балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыручыларга (Лазарева И.В., Таһирова И.Б., Павлушин С.А.) тәэмин итәргә:

- гамәлдәге санитар нормаларга һәм дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашырырга вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән кагыйдәләргә туры килүен раслый торган документ булган очракта, шулай ук янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуларны бетерү буенча күрсәтмәләр тулы күләмдә үтәлгәндә, сәламәтләндерү оешмаларын ачу;

- сәламәтләндерү оешмалары тарафыннан санитар кагыйдәләрне үтәү һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләр үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән лабораторияләр белән шартнамәләр төзү юлы белән санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны үтәү;

- кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә балаларның күмәк ялын һәм аларны савыктыруны оештыручылар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләр кертүне кисәтү, төркемле йогышлы авырулар килеп чыгуны кисәтү максатыннан чыгып киткәнче өч тәүлектән дә ким булмаган вакыт эчендә балалар коллективларын республикадан читкә җибәрүнең планлаштырыла торган сроклары турында хәбәр итү;

- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331, 351.1 статьялары таләпләренә туры китереп, сәламәтләндерү оешмаларына эшкә урнашучы затларга хөкем ителгәнлек (булмау) һәм (яки) җинаять эзәрлекләве факты булу (булмау) яисә билгеле бер җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләвен туктату турында алдан тикшерүләр оештыру;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемен автобуслар белән ташу кагыйдәләрен раслау турында»гы 2013 елның 17 декабрендәге 1177 нче номерлы карары белән расланган балаларны автобусларда йөртүне оештыру кагыйдәләре нигезендә балаларны автобусларда йөртүне оештыру;

- акарцидлы эшкәртүнең нәтиҗәлелегенә контроль үткәрү (кулланыла торган препаратка бәйле рәвештә эшкәртүдән соң 3-5 көнгә), шулай ук билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән учреждениеләр белән килешүләр төзү юлы белән

дератизация эшләренең сыйфатын контрольдә тоту (үткәрелгән дератизациядән соң 10-14 көннән соң);

- 2020 елның 20 маена кадәр балалар сәламәтләндерү лагерьларының җитәкчеләрен һәм педагогик составын хезмәтне саклау, янгын-техник минимумына һәм барлык хезмәткәрләрне билгеләнгән тәртиптә санитар-гигиеник әзерләү программалары буенча укытуны оештыру;

- башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларын һәм студентларын практика узу чорында балалар сәламәтләндерү учреждениеләрендә эшләргә җәлеп итү;

- Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Җәй» балалар һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерү, ял һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча республика үзәге» дәүләт учреждениесенә кергәннән соң 3 көн эчендә оператив мәгълүмат бирү һәм 25 числога кадәр ай саен балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру буенча финанс хисап бирү.

6. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы С.А. Павлушинга 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 23 июленә кадәр «Буревестник» спорт-сәламәтләндерү лагеренда балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештырырга һәм авыр тормыш хәлендә калган балаларга Татарстан Республикасы лагерьларына юлламалар бирергә.

- «Буревестник» палаткалы лагере эше башлану турында хәбәрнамәне Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Буа, Чүпрәле, Тәтеш, Апас районнарындагы территориаль бүлегенә вакытында тапшыруны тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы балаларга өстәмә белем бирү үзәге директоры В.И. Понедельниковага:

- «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы балаларга өстәмә белем бирү үзәге» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе базасында балалар сәламәтләндерү лагерьларына эшкә җибәрелә торган педагогик кадрларны әзерләүне тәэмин итәргә.

8. «Буревестник» лагерена ата-аналар кертеме юллама норматив бәясенең 30%ын тәшкил итүен, «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесендә 18 көн дәвамында профильле сменаларга юлламаның норматив бәясенең 25%ын тәшкил итүен, 7 көн дәвамында - 30%ын тәшкил итүен билгеләргә. Педагогик һәм хезмәт күрсәтүче персонал өчен туклану бәясе тәүлегенә 187 сум 74 тиен тәшкил итүен билгеләргә.

9. Тәтеш муниципаль районы финанс-бюджет палатасы җитәкчесе А.А. Богдановка оештырырга:

- 2020 елда балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне әлеге карар белән расланган финанслауны:

- әлеге программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны.

- «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесендә педагогик һәм хезмәт күрсәтүче персоналны тукландыру өчен 387 495 (өч йөз сиксән җиде мең дүрт йөз туксан биш сум 36 тиен) сум һәм «Буревестник» лагеры персоналын ашату өчен 26 283 (егерме алты мең сиксән өч сум) сум күләмендә акча эзләргә.

10. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ бухгалтер бүлеге начальнигы И.А. Масловага Тәтеш муниципаль районы балалар һәм яшьләрнең җәйге ялын тәэмин итүче сәламәтләндерү оешмаларының өзлексез эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне вакытында сатып алуны, товар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләргә финанс чараларын күчерүне, сметалар һәм сәламәтләндерү оешмаларының баланс тотучылардан финанс хисапларын кабул итүне тәэмин итәргә.

11. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы И.В. Лазаревага, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ башлыгы С.А. Павлушинга балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерү учреждениеләрендә булган бәхетсезлек очракларыннан ирекле иминләштерүне оештырырга.

12. Тәтеш муниципаль районы балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы сәркатибе Н.В. Николаевага тәэмин итәргә:

- беренче чиратта Тәтеш муниципаль районы эчке эшләр бүлеге һәм балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе бүлекчәләрендә учетта торучы балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештырырга;

- Тәтеш муниципаль районының балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә исәптә торучы яшүсмерләрне вакытлыча эшкә урнаштыру.

13. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы опека һәм попечительлек секторы мөдире А.С. Голодка тәрбиягә бала һәм опекунлыкка бала алган гаиләләрдәге балаларның ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыруны тәэмин итәргә.

14. Тәкъдим итәргә:

14.1. Тәтеш районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы А.С. Витинны тәэмин итәргә:

- балаларны сәламәтләндерү учреждениеләренә йөртүне оештыручы транспорт чараларының юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясенең патруль автомобильләре белән озата баруны һәм кире кайтуны;

- балалар һәм яшүсмерләр ташу куркынычсызлыгын тәэмин итәргә.

14.2. Россия ГТХМ Баш идарәсенең Татарстан Республикасы буенча 133 нче янгын-коткару бүлегенең 8 нче федераль янгынга каршы хезмәт учреждениесе начальнигы С.А. Фокинга сәламәтләндерү учреждениеләрендә һәм массакүләм ял итү урыннарында оештырылган коену урыннарын техник тикшерү һәм килешү нигезендә су объекты акваториясенең төбен чистартуда ярдәм күрсәтергә.

14.3 Кама Тамагы һәм Тәтеш муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлегенең районара бүлеге башлыгы И.И. Камбеевка балалар ял итү оешмаларында һәм массакүләм ял итү урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә.

14.4. Тәтеш үзәк район хастаханәсе баш табибы Р.Р. Салаватуллинга тәэмин итәргә:

- укудан буш һәм каникуллар вакытында вакытлыча эшкә урнашуны рәсмиләштергәндә балигъ булмаганнарга медицина тикшерүләрен уздыру өчен түләү алынмавын;

- балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру эшенә юнәлтелүче персоналга түләүсез флюорография тикшерүе үткәрүне;

- «Акчарлак» өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ гаризалары буенча балалар сәламәтләндерү лагерьларын контракт нигезендә медицина кадрлары белән тәэмин итүне;

- сәламәтләндерү оешмаларына эшкә җибәрелә торган персоналны сезонлы карау өчен түләү алынмауны.

14.5. «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Буа районындагы һәм Буа шәһәрендәге филиалының Тәтеш районындагы бүлек мөдире Н.П. Хохловага, Роспотребнадзор идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Буа, Чүпрәле, Тәтеш, Апас районнарындагы территориаль бүлеге башлыгы урынбасары О.А. Мазюкинга тәэмин итәргә:

- балаларның ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларының гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килү-килмәвенә түләү алмыйча санитар-эпидемиологик экспертиза үткәрүне;

- балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыручы персоналны гигиена кагыйдәләре белән таныштыру, лаборатор - инструменталь тикшеренүләр үткәрүне;

- уку һәм каникул вакытында балигъ булмаган балаларга вакытлыча эш белән тәэмин итүне рәсмиләштергәндә медицина тикшерүләре уздыруны;

- дәүләт биреме кысаларында Роспотребнадзор идарәсенең Татарстан Республикасы буенча Буа районы һәм Буа шәһәре территориаль бүлеге күрсәтмәсе нигезендә сәламәтләндерү учреждениесе ачылыр алдыннан дератизация һәм акарицид эшкәртүләрнең нәтиҗәлелеген тикшерү.

14.6. Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тәтеш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы О.А. Колсановага тәэмин итәргә:

- сәламәтләндерү стационар учреждениеләре, шулай ук социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре базасында авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүне оештыруны;

- олылар озатып баруында сәламәтлекләре какшаган балаларга сәламәтләндерүне һәм санитар дәвалауны оештыруны;

- республиканың сәламәтлек саклау учреждениеләре базаларында дәүләтнең аерым кайгыртуына мохтаҗ булган сәламәтлекләре какшаган балалар өчен махсуслаштырылган медик-психологик-педагогик тернәкләндерү сменаларында ял итүне оештыруны.

14.7. «Тәтеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры С.А. Цветковка, законда билгеләнгән тәртиптә, эш бирүчеләр акчасына сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартлары тудырып, укучылар составыннан торган хезмәт бригадаларының эшен тәэмин итәргә.

14.8. Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллияте директоры Т.Ю. Адаева һәм Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумы директоры И.Н. Җамалетдиновка 2019 елның июнь-август айларында студентлар отрядларының эшен тәэмин итәргә.

14.9. «Татмедиа» АҖ филиалы «Авангард» газетасы редакциясе җитәкчесе И.В. Сәфәровага, Тәтеш муниципаль районы «Тәтеш Медиа» муниципальавтоном учреждениесе директоры И.С. Морозкинага балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм мәшгульлеген оештыру буенча уңай эш тәҗрибәсен һәм сәламәтләндерү кампаниясен уздыруда аеруча актуаль проблемаларны яктыртуны тәэмин итәргә.

15. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында 2019 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында»гы Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының 2019 елның 29 мартындагы 307 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

16. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

17. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 23 гыйнварындагы
38 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы җирле үзидарә органнарының эш механизмы билгели.

1.2. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өлкәсендә җирле үзидарә органнарының килешенгән гамәлләрен тәэмин итү буенча вәкаләтле орган булып, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты оештыра торган балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия тора. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана.

1.3. Әлеге нигезләмә кысаларында балалар һәм яшьләрнең ялы өчен шәхеснең белем һәм иҗат потенциалын үстерүне, сәламәтлекне саклауны һәм ныгытуны, организмны чыныктыруны, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруны, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауны, иҗтимагый файдалы һәм җитештерү хезмәте, физик культура, спорт, туризм белән шөгыльләнүне, өлешчә яки тулысынча финансланучы шартлар һәм чаралар комплексы тора.

II. Балалар һәм яшьләрнең ял итү формалары

2.1. 2020 елда Тәтеш муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге формаларда тормышка ашырыла:
шәһәр читендәге ял лагерында профиль смена;
палатка тибындагы лагерьда профиль смена;
белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерь сменасы;
хезмәт һәм ял лагеренда смена;

2.2. Шәһәр читендәге ял лагерында профильле смена - иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы, республика, бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призерлары белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге рәвеше. Сменаның озынлыгы җәйге чорда - 18 көннән дә ким булмаска, көзге, кышкы һәм язгы чорда - 7 көннән дә ким булмаска мөмкин.

2.3. Палатка тибындагы лагерьда профильле смена - иҗади сәләтле балалар (яшь техниклар, туристлар, туган якны өйрәнүчеләр, экологлар, спортчылар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы) белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге рәвеше. Палатка тибындагы лагерьда сменаның дәвамлылыгы 7 көн.

2.4. Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьда ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге - белем бирү оешмалары укучылары белән, нигездә, белем бирү оешмасы базасында үткәрелә торган ял һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Сменаның озынлыгы каникулларның озынлыгы белән билгеләнә һәм җәйге каникуллар чорында 21 календар көн, көз, кыш һәм яз айларында җиде көннән дә ким булмаган күләмдә тәшкил итә.

2.5. Хезмәт һәм ял лагерында смена - каникуллар чорында иҗтимагый файдалы хезмәт оештыру белән бергә ял итү формасы ул, нигездә, гомуми белем бирү оешмалары базасында үткәрелә. Сменаның озынлыгы - 18 календарь көн.

2.6. Лагерьларда отрядлар балаларның яшен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып туплана. Отрядларның саны лагерьларның эш режимын түбәнәйтүгә, карап тотуга һәм оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр куелган нормативлар нигезендә билгеләнә.

## III. Балалар һәм яшьләрнең ял итү кампанияләрендә катнашучылар

3.1. Ял кампанияләрендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә даими яшәүче 7-18 яшьлек балалар һәм яшьләр катнаша.

3.2. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру балалар һәм яшьләрнең түбәндәге категорияләре буенча гамәлгә ашырыла:

иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар;

төрле дәрәҗәдәге конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призерлары;

ведомствоара профилактик исәптә, эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәсендә һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә торучы балалар (алга таба - профилактик исәптә торучы балалар);

## IV. Балалар һәм яшьләрнең ял сменаларын оештыручылар

4.1. Бирелгән компетенция кысаларында балалар һәм яшьләрнең ял сменаларын оештыручылар - «Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ, «Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ, «Акчарлак» МБУ.

4.2. «Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ иҗади сәләтле балалар һәм волонтерлар, актив әгъзалары, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балалар, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары һ.б. өчен палатка тибындагы лагерьларда профильле сменалар оештыра.

4.3. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган сменаларны оештыручы булып тора.

4.4. «Акчарлак» МБУ директоры иҗади сәләтле балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, җәйге чорда 18 көн, язгы – көзге чорда өстәмә белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен профильле сменалар оештыра.

## V. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслау тәртибе

5.1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслау законнар нигезендә түбәндәге чыганаклардан башкарыла:

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

муниципаль район чаралары;

ата-аналар (законлы вәкилләр) акчалары.

5.2. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләренең ялын оештыруга дәүләт хезмәте күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла. Әлеге пунктта күрсәтелгән норматив чыгымнар тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5.3. Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга сменаларны оештыручылар һәм анда катнашучылар киселешендә тиешле финанс елына дәүләт хезмәте күләмнәре нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга дәүләт хезмәтләре күләмнәре нормативларын исәпләү, Татарстан Республикасы халкының демо-график үзенчәлекләрен, структурасын һәм факттагы ихтыяҗларын исәпкә алып, Татарстан Республикасында халыкны социаль хезмәт күрсәтүләр (инфраструктура) белән тәэмин итүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсе нигезендә башкарыла.

5.4. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауда өлешләп катнашу күләме:

Шәһәр читендәге лагерьларда, палатка тибындагы лагерьларда профиль смена өчен балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарның 84 проценты, иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, мәгариф оешмасы лагеренда сменалар үткәрү өчен тиешле финанс елына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарның 84 проценты;

5.5. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча җирле бюджетларга әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән нормалардан чыгып исәпләнелә торган субсидияләр бирү юлы белән финанслашуны тәэмин итә. Күрсәтелгән субсидияләрне бирү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында әлеге максатларга каралган акчалар күләме чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә һәм шартларда гамәлгә ашырыла.

## VI. Балалар һәм яшьләр ялы өчен ата-аналар түләве күләмен билгеләү тәртибе

6.1. Лагерьларда балалар һәм яшьләрнең ял иткән өчен ата-аналар түләве күләме Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан арта. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарның 15 процентыннан артыгын билгеләргә киңәш ителә,әмма ял итү төрләренә карап юлламаның факттагы бәясеннән 50 проценттан да артмый.

6.2. Башкарма комитет юлламаның бәясен, күрсәтелә торган хезмәтләрнең үзкыйммәтенә тигез итеп билгели. Норматив чыгымнар реаль чыгымнарга туры килмәсә, путевка Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчаларның факттагы бәясе арасындагы аерма ата-аналар (яки законлы вәкилләр), оешмалар тарафыннан түләнә.

## VII. Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьда балаларның ялын оештыру тәртибе

7.1. Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьга ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы нигезендә белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар җибәрелә.

7.2. Ата-ана гаризасы тиешле мәгариф органы тарафыннан расланган форма буенча бала укый торган белем бирү оешмасына тапшырыла.

7.3. Мәгариф оешмасы ата-аналар гаризасы нигезендә (закон вәкилләре) көндезге лагерьга җибәрелә торган балалар исемлеген формалаштыра һәм аны район мәгариф бүлегенә тапшыра. Исемлектә указлар саклана:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән ата-ананың фамилиясе, исеме, атасының исеме (яки законлы вәкиленең);

дата, ай, туган ел, бала җенесе;

ата-ананың эш урыны (яки законлы вәкилнең эш урыны);

бала укый торган белем бирү оешмасы исеме;

бала укый торган сыйныф.

Мәгариф бүлеге гомуми белем бирү оешмалары балалары исемлекләре нигезендә муниципаль район балаларының җыелма исемлеген һәм белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьларда аларның ялын оештыру планын төзи.

7.4. Мәгариф оешмасы оештырган, «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 7 февралендәге 73 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районында көндезге ял лагерьларында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру планы тиешле финанс елына хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары чикләрендә төзелә:

лагерьлар оештырылачак белем бирү оешмаларының исемнәре;

лагерьларда оештырылган урыннар саны;
лагерьларда сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;
балаларны лагерьлар оештырылачак белем бирү оешмалары буенча бүлү.

7.5. Көндезге лагерьларда балаларның ялын оештыру планы Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана.

7.6. Өч көн эчендә мәгариф бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлык адресына ялны оештыруга килүчеләр саны турында мәгълүмат җибәрә.

7.7. Ай саен, 25 нче числога кадәр, район мәгариф бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы адресына ял итүне оештыру буенча мониторинг җибәрә.

7.8. Хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар тәмамланганнан соң, мәгариф бүлеге Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы адресына хезмәт һәм ял лагерьлары эшчәнлеге турында мәгълүмат җибәрә.

## VIII. Хезмәт һәм ял лагерьларында сменаны оештыру тәртибе

8.1. Хезмәт һәм ял лагерьларына белем бирү оешмалары укучылары иҗтимагый файдалы хезмәткә җәлеп ителъ максатыннан җибәрелә.

